Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Кузнечиха авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР

№ 2 01.02.2023

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кузнечиха авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, «2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2023 елның 30 гыйнварындагы 119 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кузнечиха авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 февраленнән Спас муниципаль районының Кузнечиха авыл җирлегендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Кузнечиха авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Бураково авыл җирлеге битендә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында http:/www.spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кузнечиха авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Ибраһимов